# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **07.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Әгерҗе авыл җирлегенә керүче Мәнәвез
авылында 2020 елдаүзарасалым жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегендә халык җыены карар бирә:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 (биш йөз) сумк үләмендә, 1 төркем инвалидлар, укучыларның көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:

   - Мәнәвез авылы, Чулпан, Болотная урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эшләр өчен килешү буенча түләү);;
   - Мәнәвез авылы зиратында проблемалы агачларны кистерү;
   - Мәнәвез авылында («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халык – ара өлкәннәр көне», “Корбан”) бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;
   - трактор йөртүчесенә хезмәте өчен түләү;
   - Центральная урамына ясалма тигезсезлек сатып алу һәм урнаштыру;
   - Сосновая урамы буенча металл барьер коймасын урнаштыру.

3.Әлеге халык жыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Әгерҗе авылы, Г.Ахметова урамы, 14а йорт адресы буенча, Мәнәвез авылы, С.Хаким урамы, 1а йорт адресы буенча, Мәнәвез авылы, Центральная урамы, 53 йорт белән 55 йорты арасында урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әгерҗе авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Хәсәнов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН АЗНАКАЕВСКИЙ
АГЕРЗИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1602002575
КПП 164301001